ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КРУГЛОЕ ПОЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

КАРАР

«03» апрель 2024 ел № 2

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге составына керүче Круглое Поле поселогы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 29 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 29 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге Круглое Поле поселогы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге Круглое Поле авылында гражданнар җыенын билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Тукай муниципаль районы «Круглое Поле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Круглое Поле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге Советының 2019 елның 08 ноябрендәге 57/1 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге составына керүче Круглое Поле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 29 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 29 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге Круглое Поле авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2024 елның 14 апрель 13.00 сәгатькә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез үзгәрешләр кертергә ризамы:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге составына керүче Круглое Поле поселогы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 29 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына:

«-торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Круглое Поле бистәсендәге юлларны ремонтлау);

- су белән тәэмин итү һәм су бүлү системаларын, суэтем башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Круглое Поле бистәсендә материаллар сатып алу һәм канализация челтәрләрен ремонтлау; Круглое Поле бистәсендә суүткәргеч челтәрләрен реконструкцияләү);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Круглое Поле бистәсендә материаллар сатып алу, мафларны урнаштыру һәм ремонтлау; Круглое Поле бистәсендә "Тимер юлчы" паркы территориясен төзекләндерү);

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка ярдәмче станцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Круглое Поле бистәсендә урам яктыртуын сатып алу һәм урнаштыру);

- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү (Круглое Поле бистәсендәге зиратны төзекләндерү (койманы ремонтлау, буяу һәм күчерү, инвентарьны саклау өчен хозблокны ремонтлау).»

2) түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 29 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге Круголе Поле поселогы гражданнар җыены карарына:

«-торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Круглое Поле бистәсендәге юлларны ремонтлау);

- су белән тәэмин итү һәм су бүлү системаларын, суэтем башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Круглое Поле бистәсендә материаллар сатып алу һәм канализация челтәрләрен ремонтлау; Круглое Поле бистәсендә суүткәргеч челтәрләрен реконструкцияләү);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Круглое Поле бистәсендә материаллар сатып алу, мафларны урнаштыру һәм ремонтлау; Круглое Поле бистәсендә "Тимер юлчы" паркы территориясен төзекләндерү);

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка ярдәмче станцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Круглое Поле бистәсендә урам яктыртуын сатып алу һәм урнаштыру);

- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү (Круглое Поле бистәсендәге зиратны төзекләндерү (койманы ремонтлау, буяу һәм күчерү, инвентарьны саклау өчен хозблокны ремонтлау).»

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Круглое Поле авыл җирлеге, Круглое Поле поселогы, Вокзал ур., 7 йорт (МФЦ «Юность»_бинасы).

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тукай муниципаль районы
Круглое Поле авыл җирлеге Башлыгы О.Л Маркова